ГЛАВНОЕ УПРАВЛЕНИЕ
ВЕТЕРИНАРИИ
КАБИНЕТА МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР
КАБИНЕТЫНЫҢ
БАШ ВЕТЕРИНАРИЯ ИДАРӘСЕ

**БОЕРЫК** **БОЕРЫК**

10.10.2013 Казан ш. № 366-к

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсенең 01.09.2010 елның 202-к номерлы “Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсе дәүләт граждан хезмәте вазыйфасына билгеләнгәндә гражданнар һәм Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре үз керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирергә тиешле Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлеген раслау турында”гы боерыкка үзгәреләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсенең 2010 елның 1 сентябрендәге “Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсендә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфасына билгеләнгәндә гражданнар һәм Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре үз керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр, шулай ук үзләренең керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирергә тиешле дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлеген раслау турында” 202-к номерлы боерыгын, (алга таба боерык) “Коррупциягә каршы тору турында” 25.12.2008 ел, № 273-ФЗ Федераль закон таләпләре нигезендә, (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсенең 05.06.2012 елның № 184-к боерыгы редакциясендә) БОЕРАМ:

1. Әлеге боерыкка түбәндәге үзгәрешләрне кертергә::

1 пунктның 1.1-1.3 бүлекчәләрендә түбәндәгечә редакциялəп бәян итәргә:

«Югарыда күрсәтелгән исемлеккә кертелгән дәүләт хезмәте вазыйфасын биләгән граждан, дәүләт хезмәте эштән киткәннән соң, ике ел эчендә оешмада хезмәт килешүе шартларында, гражданлык-хокукый килешү шартларында, әгәр әлеге оешма белән дәүләт идарәсенең аерым функцияләре дәүләт хезмәткәренең вазыйфа (хезмәт) бурычларына керсә, дәүләт хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча тиешле комиссия ризалыгы белән

вазыйфаларны биләү һәм (яки) әлеге оешмада эш башкару (әлеге оешмада хезмәт күрсәтү) яки ай дәвамында йөз мең сумнан артык бәяле эшләр башкару хокукына ия.

1.2. Исемлеккә кертелгән дәүләт хезмәте вазыйфаларын биләгән граждан, Дәүләт хезмәтеннән азат ителгәннән соң ике ел дәвамында әлеге пунктның 1.1 пунктында күрсәтелгән эшләрне башкару (хезмәт күрсәтү) өчен хезмәт яки гражданлык-хокукый шартнамәләре төзегәндә эш бирүчегә үз хезмәтенең соңгы урыны турында хәбәр итәргә бурычлы.

1.3. Әлеге пунктның 1.2 пунктчасында каралган таләпләрне дәүләт хезмәте вазыйфаларын биләгән граждан тарафыннан дәүләт хезмәтеннән азат ителгәннән соң әлеге граждан белән төзелгән эшләрне башкаруга (хезмәт күрсәтүгә) хезмәт яисә граждан-хокукый шартнамәсенең туктатылуына китерә.”.

Татарстан Республикасы Министрлар
Кабинетының Баш ветеринария
идарәсе башлыгы вазыйфаларын башкаручы Р.Н.Әгъләмов